ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.07.2024 г. Заинск № 386

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы "Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенең 2 бүлегенең 2.1. пунктын (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2014 ел № 157, 10.02.2014 ел № 253, 12.10.2015 ел № 1792, 26.04.2016 ел № 777, 21.03.2017 ел № 466, 24.01.2018 ел № 73, 04.09.2019 ел № 472, 03.02.2021 ел № 55, 06.04.2021 по 202, 14.03.2023ел № 175 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге эчтәлектәге l пунктчасы белән тулыландырырга:

«l) күп балалы гаиләләргә һәр балага туу турында таныклык күчермәләре сыйфатын раслаучы документлар буларак.»

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42